КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 34

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче; 2018 ел, 31 май, 411 нче; 2019 ел, 15 гыйнвар, 4 нче; 2020 ел, 3 март, 162 нче; 2020 ел, 21 апрель, 310 нчы; 2020 ел, 27 июль, 627 нче; 2021 ел, 1 октябрь, 942 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1358 нче; 2022 ел, 22 февраль, 154 нче; 2022 ел, 18 август, 854 нче; 2023 ел, 6 апрель, 419 нчы, 2023 ел, 3 июль, 773 нче, 2023 ел, 17 август, 984 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге), урман саклау (01.06.14*).»;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасында:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урманнарны саклауны (шул исәптән урман янгыннарын тикшереп тору зоналарын билгеләүне, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне, урман янгыннарын сүндерүне, моңа урман янгыннарын локальләштерү һәм бетерү максатларында шартлату эшләрен үтәү һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында явым-төшемне ясалма булдыру чараларын гамәлгә ашыру, шулай ук экстрен җавап бирү чараларын гамәлгә ашыру керми), урманнарны яклауны (урманны яклау районыннан һәм дәүләт урман патологиясе мониторингыннан тыш), урманнарны торгызуны (урман

орлыкландырудан тыш, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын һәм урманнарны яңадан торгызуга дәүләт мониторингы фондын төзүдән тыш), урман үрчетүне, шул исәптән:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшли;

урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшли һәм раслый.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче, 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре координаторына, «01.06.14» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге), урман саклау».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин